**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5853**
**09.11.2020**

Башкарма комитетның муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру өлкәсендәге аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Заказчыларга, контракт хезмәтләренә, контракт идарәчеләренә, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны гамәлгә ашыру комиссияләренә һәм аларның әгъзаларына, вәкаләтле органнарга, вәкаләтле учреждениеләргә, махсуслаштырылган оешмаларга, электрон мәйданчыкларның операторларына, махсуслаштырылган электрон мәйданчыкларның операторларына карата товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында һәм шикаятьләр, планлы һәм планнан тыш тикшерүләр, алар буенча кабул ителгән карарлар һәм бирелгән күрсәтмәләр реестрын алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 октябрендәге 1576 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2018 елның 1 августында «Челнинские известия» газетасының 55 нче санында басылып чыккан һәм 2018 елның 13 июлендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2018 елның 10 июлендәге 3843 номерлы Башкарма комитет карары;

2) 2019 елның 23 августында «Челнинские известия» газетасының 62 нче санында басылып чыккан һәм 2019 елның 21 августында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3843 номерлы карары белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру

буенча административ регламентка үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 19 августындагы 4266 номерлы Башкарма комитет карары;

3) 2020 елның 27 маенда «Челнинские известия» газетасының 38 нче санында басылып чыккан һәм 2020 елның 27 маенда Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Башкарма комитетның аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 19 маендагы 2315 номерлы Башкарма комитет карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                Ф.Ш. Салахов